# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**8 декабрь 2025 ел** **№8**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Бүләк Сарлы авыл җирлегенең торак
пунктында 2025 елда гражданнарга
үзара салым кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге Уставы нигезендә

Карар кылдым:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бүләк авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге төрдәге чара белән тулыландырып җибәрергә:
"- ремонт, коймаларны кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (Бүләк авылындагы зират коймасын алмаштыру һәм материал сатып алу).».
3. Әлеге карарны Сар мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге башлыгы И.М.Камалетдинов